**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 сентябрендәге 4054 номерлы карары**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы кысаларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында**

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы кысаларында, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы « Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2024 елның 27 сентябрендә 00.00 сәгатьтән 23.59 сәгатькә кадәр Пушкин урамы буенча К.Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне билгеләргә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлы юл билгеләрен урнаштыру схемасын төзергә һәм аларны урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны урнаштырырга;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре

җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) күрсәтелгән урам-юл челтәре участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим.**

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**